| | | |
|---|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 29 июнь № 468

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 16 июнь, 411 нче, 2014 ел, 25 октябрь, 777 нче, 2015 ел, 25 февраль, 115 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Дәүләт программасының максатлары һәм бурычлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Дәүләт программасының максатлары һәм бурычлары | Максатлары:<br>Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексын инновацион үстерү нигезендә эчке һәм тышкы базарларда авыл хуҗалыгы продукциясенең конкурентлык сәләтен үстерү;<br>агросәнәгать комплексы товар җитештерүчеләрнең финанс тотрыклылыгын күтәрү; |

| | |
|---|---|
| | җир ресурсларын һәм башка ресурсларны торгызу, авыл хуҗалыгында алардан файдалану нәтиҗәлелеген күтәрү, шулай ук җитештерүне экологизацияләү;<br>авыл территорияләрен тотрыклы үстерү.<br>Бурычлары:<br>импортны алыштыруга юнәлдерелгән үсемлекчелек продукциясенең төп төрләрен җитештерү һәм эшкәртү үсешен стимуллаштыру;<br>импортны алыштыруга юнәлдерелгән терлекчелек продукциясе һәм аны эшкәртү продуктларын җитештерү нәтиҗәлелеген комплекслы үстерү һәм күтәрү өчен шартлар тудыру;<br>итле терлекчелекнең конкурентлык сәләтен үстерү;<br>хуҗалык итүнең кече формаларындагы авыл хуҗалыгы эшчәнлегенә һәм авыл хуҗалыгына карамаган эшчәнлеккә булышлык күрсәтү һәм аны алга таба үстерү, авыл җирлегендә халыкның тормыш сыйфатын яхшырту;<br>үсемлекчелектә, терлекчелектә һәм авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртүдә энергия ресурсларын саклау хисабына җитештерүне техник һәм технологик модернизацияләү нигезендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре продукциясенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм конкурентлык сәләтен үстерү;<br>авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу өлкәсендә дәүләт хакимияте органнарының һәм ведомство карамагындагы учреждениеләрнең нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итү;<br>авыл җирлегендә уңайлы тормыш шартлары тудыру, авылга һәм авылда яшәү рәвешенә карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру;<br>авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләргә комплекслы мелиорация үткәрү;<br>авыл хуҗалыгы продукциясен сатуны тәэмин итү, аны сезонлап саклау һәм аз-азлап сату өчен шартлар тудыру хисабына аның товарлылыгын күтәрү»; |

«Дәүләт программасының максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр» юлына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2020 елга авыл хуҗалыгы продукциясен төп җитештерүгә чыгымнар структурасында энергия ресурслары сатып алуга чыгымнарның чагыштырма авырлыгын 10,0 процентка кадәр җиткерү»;»;

Программаның II бүлегендәге 1 бүлекчәдә җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җитештерү өлкәсендә – авыл хуҗалыгының импортны алыштыручы ярдәмче тармакларын (сөтле һәм итле терлекчелек, кошчылык, дуңгызчылык, ашлык, бәрәңге, яшелчәләр, җимешләр һәм җиләкләр җитештерү) үстерү, техник яңадан кораллану, азык-төлек һәм эшкәртү сәнәгатен үстерү;»;

Программаның II бүлегендәге 2 бүлекчәдә:

җиденче һәм сигезенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«импортны алыштыруга юнәлдерелгән үсемлекчелек продукциясенең төп төрләрен җитештерү һәм эшкәртү үсешен стимуллаштыру;

импортны алыштыруга юнәлдерелгән терлекчелек продукциясе һәм аны эшкәртү продуктларын җитештерү нәтиҗәлелеген комплекслы үстерү һәм күтәрү өчен шартлар тудыру;»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үсемлекчелектә, терлекчелектә һәм авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртүдә энергия ресурсларын саклау хисабына җитештерүне техник һәм технологик модернизацияләү нигезендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре продукциясенең нәтиҗәлелеген һәм конкурентлык сәләтен үстерү;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«авыл хуҗалыгы продукциясен сатуны тәэмин итү, аны сезонлап саклау һәм аз-азлап сату өчен шартлар тудыру хисабына аның товарлылыгын күтәрү.»;

Программаның II бүлегендәге 3 бүлекчәдә:

унөченче абзацны ундүртенче абзац дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле унөченче абзац өстәргә:

«авыл хуҗалыгы продукциясен төп җитештерүгә чыгымнар структурасында энергия ресурслары сатып алуга чыгымнарның чагыштырма авырлыгы;»;

Программаның 1 таблицасында:

«Бурыч исеме» графасында:

беренче һәм икенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«импортны алыштыруга юнәлдерелгән үсемлекчелек продукциясенең төп төрләрен җитештерү һәм эшкәртү үсешен стимуллаштыру;

импортны алыштыруга юнәлдерелгән терлекчелек продукциясе һәм аны эшкәртү продуктларын җитештерү нәтиҗәлелеген комплекслы үстерү һәм күтәрү өчен шартлар тудыру;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үсемлекчелектә, терлекчелектә һәм авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртүдә энергия ресурсларын саклау хисабына җитештерүне техник һәм технологик модернизацияләү нигезендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре продукциясенең нәтиҗәлелеген һәм конкурентлык сәләтен үстерү;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«авыл хуҗалыгы продукциясен сатуны тәэмин итү, аны сезонлап саклау һәм аз-азлап сату өчен шартлар тудыру хисабына аның товарлылыгын күтәрү.»;

«Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре» һәм «Индикаторларның мәгънәләре» графаларына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Авыл хуҗалыгы продукциясен төп җитештерүгә чыгымнар структурасында энергия ресурслары сатып алуга чыгымнарның чагыштырма авырлыгы, процент | 9,9 | 10,0 | 10,3 | 10,3 | 10,2 | 10,2 | 10,1 | 10,1 | 10,0»; |

«Үсемлекчелек ярдәмче тармагын, үсемлекчелек продукциясен эшкәртү һәм реализацияләүне үстерү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программ паспортының «Ярдәмче программаның максаты» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Импортны алыштыруга юнәлдерелгән үсемлекчелек продукциясенең төп төрләрен җитештерү һәм эшкәртү үсешен стимуллаштыру»;

«Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр» юлына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Түбәндәгеләр артымы:

2015 елдан 2020 елга кадәр ачык грунтта үскән бәрәңге һәм яшелчәләр саклау куәте – 38,0 мең тоннага;

2015 елдан 2020 елга кадәр авыл хуҗалыгы оешмаларында, крестьян (фермер) хуҗалыкларында, индивидуаль эшмәкәрләрне кертеп, ябык грунтта үсә торган яшелчәләр җитештерү – 4,0 мең тоннага;

2015 елдан 2020 елга кадәр теплицалар мәйданы – 7,5 гектарга;

2015 елдан 2020 елга кадәр заманча ашлык саклау урыннары һәм элеваторлар куәте – бер тапкыр саклау 64 мең тоннага;

2015 елдан 2020 елга кадәр шикәр саклау куәте – бер тапкыр саклау 70,5 мең тоннага.»;

ярдәмче программаның II бүлегендәге 2 бүлекчәдә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программаның максаты – импортны алыштыруга юнәлдерелгән үсемлекчелек продукциясенең төп төрләрен җитештерү һәм эшкәртү үсешен стимуллаштыру.»;

утыз тугызынчы абзацны утыз бишенче абзац дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле егерме тугызынчы – утыз дүртенче абзацлар өстәргә:

«түбәндәгеләр артымы:

2015 елдан 2020 елга кадәр ачык грунтта үскән бәрәңге һәм яшелчәләр саклау куәте – 38 мең тоннага;

2015 елдан 2020 елга кадәр авыл хуҗалыгы оешмаларында, крестьян (фермер) хуҗалыкларында, индивидуаль эшмәкәрләрне кертеп, ябык грунтта үсә торган яшелчәләр җитештерү – 4,0 мең тоннага;

2015 елдан 2020 елга кадәр теплицалар мәйданы – 7,5 гектарга;

2015 елдан 2020 елга кадәр заманча ашлык саклау урыннары һәм элеваторлар куәте – бер тапкыр саклау 64 мең тоннага;

2015 елдан 2020 елга кадәр шикәр саклау куәте – бер тапкыр саклау 70,5 мең тоннага.»;

Программаның 3 таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 таблица

2013 – 2020 елларга «Үсемлекчелек ярдәмче тармагын, үсемлекчелек продукциясен эшкәртү һәм реализацияләүне үстерү» ярдәмче программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

Ярдәмче программаның максаты – импортны алыштыруга юнәлдерелгән үсемлекчелек продукциясенең төп төрләрен җитештерү һәм эшкәртү үсешен стимуллаштыру

| Бурыч исеме | Төп чаралар исеме | Үтәүчеләр | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар мәгънәләре | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2012 (база) ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| Үсемлекчелек продукциясенең төп төрләрен җитештерү һәм эшкәртү күләмнәрен арттыру | Туфракның уңдырышлылыгын күтәрү һәм авыл хуҗалыгы биләмәләренең файдаланылмый торган җирләрен авыл хуҗалыгы әйләнешенә кертү | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | Барлык категорияләрдәге хуҗалыкларда үсемлекчелек продукциясе җитештерү, мең тонна | | | | | | | | | |
| | | | бөртеклеләр һәм бөртекле-кузаклылар | 3200 | 4300 | 4400 | 4500 | 4600 | 4700 | 4800 | 5000 | 5200 |
| | | | җитен сүсе һәм киндер сүсе | 1 | 1 | 1,05 | 1,1 | 1,15 | 1,2 | 1,25 | 1,3 | 1,35 |
| | | | шикәр чөгендере | 2010,8 | 1750 | 1800 | 1850 | 1900 | 1950 | 2000 | 2050 | 2100 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Үсемлекчелек ярдәмче тармагына, аның продукциясен эшкәртүгә, үсемлекчелек продукциясе базарлары инфраструктурасын һәм логистик тәэмин ителешен үстерүгә кредит бирү буенча дәүләт ярдәме | | бәрәңге | 1376,4 | 1200 | 1250 | 1300 | 1350 | 1400 | 1450 | 1500 | 1500 |
| | | | ачык грунтта үскән яшелчәләр | 245 | 265 | 264,5 | 264,5 | 265,6 | 265,6 | 265,5 | 265,5 | 265,5 |
| | | | җимеш-җиләк продукциясе | 22,3 | 22,4 | 22,9 | 23,1 | 23,1 | 23,1 | 23,1 | 23,1 | 23,1 |
| | | | майлы үсемлекләр, шул исәптән көнбагыш | 35,8 | 36,6 | 37,5 | 38,4 | 39,3 | 40,3 | 41,2 | 42,3 | 43,2 |
| | | | рапс | 101 | 103,4 | 105,9 | 108,4 | 111 | 113,7 | 116,4 | 119,2 | 122,1 |
| | | | соя | 0,2 | 0,2 | 0,2 | 0,2 | 0,2 | 0,2 | 0,2 | 0,2 | 0,2 |
| | | | Бөртекле культуралардан, яшелчә һәм башка үсемлек культураларыннан он, катнашмалар җитештерү, мең тонна | 241 | 244,1 | 245,1 | 245,6 | 246,1 | 247,3 | 248,6 | 249,8 | 251,1 |
| | | | Ярма җитештерү, мең тонна | 13,3 | 13,6 | 13,7 | 13,8 | 13,9 | 14 | 14,1 | 14,2 | 14,3 |
| | | | Диетик һәм микронутриент- | 2,8 | 3 | 3,1 | 3,4 | 3,7 | 4,2 | 5,6 | 7,1 | 8,5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | лар белән баетылган икмәк-күмәч ризыклары җитештерү, мең тонна | | | | | | | | | |
| Үсемлекчелек продукциясенең төп төрләрен җитештерү һәм эшкәртү күләмнәрен арттыру | | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | Чистартылмаган үсемлек мае һәм аның фракцияләрен җитештерү, мең тонна | 84,2 | 93,4 | 94,6 | 95,8 | 97,1 | 98,6 | 99,5 | 101,4 | 102,6 |
| | | | Шикәр чөгендереннән каты ак шикәр җитештерү, мең тонна | 149,6 | 152,4 | 155,9 | 159,3 | 162,8 | 166,3 | 180,1 | 183,5 | 187 |
| | | | Җимеш-яшелчә консервалары җитештерү, млн.шартлы банка | 127,5 | 132,2 | 136,2 | 140,3 | 144,5 | 148,5 | 152,8 | 157,3 | 161,7 |
| | Затлы орлыкчылыкны үстерү | | Затлы орлыклар чәчелә торган мәйданның чагыштырма авырлыгы, % | 18 | 18 | 19 | 19 | 19 | 19 | 20 | 20 | 20 |
| | Күпьеллык үсентеләрне утыртуга һәм | | Күпьеллык үсентеләрне утырту мәйданы, | 0,2 | 0,2 | 0,2 | 0,2 | 0,2 | 0,2 | 0,2 | 0,2 | 0,2 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | карап үстерүгә булышлык күрсәтү | | мең гектар | | | | | | | | | |
| | Үсемлекчелек тармакларындагы куркынычларны тикшерүдә тоту | | Авыл хуҗалыгы культураларының гомуми мәйданында иминиятләштерелгән чәчүлекләрнең чагыштырма авырлыгы, % | 46,6 | 40 | 40 | 40 | 40 | 40 | 40 | 40 | 40 |
| | | | Ачык грунтта үскән бәрәңге һәм яшелчәләр саклау куәтенең артымы, мең тонна | - | - | - | 7,0 | 7,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 |
| | | | Авыл хуҗалыгы оешмаларында, крестьян (фермер) хуҗалыкларында, индивидуаль эшмәкәрләрне кертеп, ябык грунтта үсә торган яшелчәләр җитештерү артымы, мең тонна | - | - | - | 1,0 | 0,6 | 0,6 | 0,6 | 0,6 | 0,6 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Теплицалар мәй-даннары артымы, гектар | - | - | - | 1,5 | 1,2 | 1,2 | 1,2 | 1,2 | 1,2 |
| | | | Заманча ашлык саклау урыннары һәм элеваторлар куәте артымы, мең тонна | - | - | - | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 11,0 | 11,0 | 12,0 |
| | | | Шикәр саклау күәте артымы, мең тонна | - | - | - | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 11,0 | 14,5 | 15,0»;» |

«Терлекчелек ярдәмче тармагын, терлекчелек продукциясен эшкәртү һәм реализацияләүне үстерү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортының «Ярдәмче программаның максаты» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Импортны алыштыруга юнәлдерелгән терлекчелек продукциясе һәм аны эшкәртү продуктларын җитештерү нәтиҗәлелеген комплекслы үстерү һәм күтәрү өчен шартлар тудыру»;

«Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр» юлында түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Авыл хуҗалыгы оешмаларында, крестьян (фермер) хуҗалыкларында, индивидуаль эшмәкәрләрне кертеп, сөт товарлылыгының үсеше – 90 проценттан 92,5 процентка кадәр;

сөтчелек юнәлешендәге мөгезле эре терлекнең ана башларының гомуми санында сөтчелек юнәлешендәге мөгезле эре терлекнең ана башларының тәңгәлләштерелгән саны чагыштырма авырлыгы үсеше – 100 процентка кадәр;

2015 – 2020 елларда сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплексларында (сөт фермаларында) эксплуатациягә кертелгән терлек урыннары санын 7,4 мең терлек урынына арттыру;

авыл хуҗалыгы хайваннарының нәселле ана башлары санының узган ел дәрәҗәсенә карата 100 процент сакланышы;

итле токымнан булган нәселле яшь мөгезле эре терлекне бер елга 100 ана башка 10 баш реализацияләү;

сөтле токымнан булган нәселле яшь мөгезле эре терлекне бер елга 100 ана башка 10 баш реализацияләү;

селекция-генетика үзәкләре төзү, 1 берәмлек;

сөт сыерларының гомуми баш санында сөтчелек юнәлешендәге нәселле сыерларның чагыштырма авырлыгы үсеше – 23,5 проценттан 24,0 процентка кадәр.»;

ярдәмче программаның II бүлегендәге 2 бүлекчәдә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программаның максаты – импортны алыштыруга юнәлдерелгән терлекчелек продукциясе һәм аны эшкәртү продуктларын җитештерү нәтиҗәлелеген комплекслы үстерү һәм күтәрү өчен шартлар тудыру.»;

унөченче – унсигезенче абзацларны тиешенчә егерме беренче – егерме алтынчы абзацлар дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле унөченче – егерменче абзацлар өстәргә:

«авыл хуҗалыгы оешмаларында, крестьян (фермер) хуҗалыкларында, индивидуаль эшмәкәрләрне кертеп, сөт товарлылыгының үсеше – 90 проценттан 92,5 процентка кадәр;

сөтчелек юнәлешендәге мөгезле эре терлекнең ана башларының гомуми санында сөтчелек юнәлешендәге мөгезле эре терлекнең ана башларының тәңгәлләштерелгән саны чагыштырма авырлыгы үсеше – 100 процентка кадәр;

2015 – 2020 елларда сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплексларында (сөт фермаларында) эксплуатациягә кертелгән терлек урыннары санын 7,4 мең

терлек урынына арттыру;

авыл хуҗалыгы хайваннарының нәселле ана башлары санын узган ел дәрәҗәсенә карата 100 процент саклау;

итле токымнан булган нәселле яшь мөгезле эре терлекне бер елга 100 ана башка 10 баш реализацияләү;

сөтле токымнан булган нәселле яшь мөгезле эре терлекне бер елга 100 ана башка 10 баш реализацияләү;

селекция-генетика үзәкләре төзү, 1 берәмлек;

сөт сыерларының гомуми баш санында сөтчелек юнәлешендәге нәселле сыерларның чагыштырма авырлыгы үсеше – 23,5 проценттан 24,0 процентка кадәр;»;

Программаның 5 таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 таблица

2013 – 2020 елларга «Терлекчелек ярдәмче тармагын,
терлекчелек продукциясен эшкәртү һәм реализацияләүне үстерү» ярдәмче программасының
максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

Ярдәмче программаның максаты – импортны алыштыруга юнәлдерелгән терлекчелек продукциясе һәм аны эшкәртү продуктларын җитештерү нәтиҗәлелеген комплекслы үстерү һәм күтәрү өчен шартлар тудыру

| Бурыч исеме | Төп чаралар исеме | Үтәүчеләр | Соңгы нәтиҗәләрне җәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар мәгънәләре | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2012 (база) ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| Сөтле һәм итле терлекчелек, кошчылык продукциясен җитештерү һәм эшкәртү күләмнәрен арттыру | Сөтле терлекчелекне үстерү | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе | Барлык категорияләрдәге хуҗалыкларда сөт җитештерү, млн.тонна | 1,888 | 1,960 | 1,963 | 1,984 | 2,015 | 2,066 | 2,090 | 2,232 | 2,335 |
| | Нәселле терлекчелек | | Барлык категорияләрдәге хуҗалыкларда сугымга терлек һәм кошлар җитештерү (тере авырлыкта), млн.тонна | 0,456 | 0,440 | 0,455 | 0,470 | 0,496 | 0,507 | 0,518 | 0,529 | 0,540 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Терлекчелек ярдәмче тармагына, аның продукциясен эшкәртүгә, терлекчелек продукциясе базарлары инфраструктурасын һәм логистик тәэмин ителешен үстерүгә кредит бирү буенча дәүләт ярдәме | | Терлек чалу һәм аны беренчел эшкәртү буенча җитештерү куәте артымы, мең тонна | 14,2 | 14,4 | 2,1 | 2,7 | 3,6 | 0,9 | 1,1 | 1,2 | 1,4 |
| | | | Йомырка җитештерү, млн.данә | 1120,2 | 1100 | 1150 | 1180 | 1200 | 1230 | 1250 | 1270 | 1300 |
| | | | Сырлар һәм сыр продуктлары җитештерү, мең тонна | 31,5 | 33,1 | 33,1 | 33,5 | 33,6 | 33,7 | 34,1 | 34,4 | 34,7 |
| | | | Сыер мае җитештерү, мең тонна | 21,7 | 22,5 | 22,5 | 22,6 | 22,9 | 23 | 23,3 | 23,5 | 23,8 |
| Халыкның традицион тормыш рәвеше һәм мәшгульлеге саклануын тәэмин итүче | Сарык һәм кәҗә үрчетүне үстерү | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, | Авыл хуҗалыгы оешмаларында, крестьян (фемер) хуҗалыкларында, индивидуаль эшмәкәрләрне кертеп, | 23,0 | 25,1 | 25,5 | 26,0 | 26,4 | 26,9 | 27,4 | 27,8 | 28,5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| терлекчелек-нең социаль әһәмияттәге тармакларын үстерү | | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе | ана кәҗәләр һәм ана сарыкларның баш саны, мең баш | | | | | | | | | |
| Хайваннар-ның һәм кош-ларның йо-гышлы авыру-лары барлык-ка килүне һәм таралуны кисәтү | Эпизоотиягә каршы чаралар үткәрүне тәэмин итү | | Тиз бирешүчән хайваннарның баш санындагы дуңгызларга аф-рика чумасына тикшеренүләр үткәрү, дуңгыз-ларның баш са-ныннан үткәрел-гән тикшеренү-ләр проценты | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 |
| | Терлекчелек тармакларын-дагы куркы-нычларны тикшерүдә тоту | | Татарстан Рес-публикасы тер-риториясендә дуңгызларның африка чумасын барлыкка ките-рүчене ачыклау дәрәҗәсе, тик-шеренүләрнең гомуми санын-нан уңай про-балар проценты | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Авыл хуҗалыгы оешмаларында, крестьян (фермер) хуҗалыкларында, индивидуаль эшмәкәрләрне кертеп, сөт товарлылыгы, процент | - | - | - | 90 | 90,5 | 91 | 91,5 | 92 | 92,5 |
| | | | Сөтчелек юнәлешендәге мөгезле эре терлекнең ана башларының гомуми санында сөтчелек юнәлешендәге мөгезле эре терлекнең ана башларының тәңгәлләштерелгән саны чагыштырма авырлыгы, процент | - | - | - | - | - | 50 | 80 | 90 | 100 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплексларында (сөт фермаларында) эксплуатациягә кертелгән терлек урыннары саны, мең терлек урыны | - | - | - | 1,0 | 1,2 | 1,6 | 1,2 | 1,2 | 1,2 |
| | | | Авыл хуҗалыгы хайваннарының нәселле ана башлары санының узган ел дәрәҗәсенә карата саклანышы, процент | - | - | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | | Итле токымнан булган нәселле яшь мөгезле эре терлекне 100 ана башка реализацияләү, баш саны | - | - | - | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Сөтле токымнан булган нәселле яшь мөгезле эре терлекне 100 ана башка реализацияләү, баш саны | - | - | - | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 |
| | | | Гамәлгә кертелгән селекция-генетика үзәкләре саны, берәмлек | - | - | - | - | - | 1 | - | - | - |
| | | | Сөт сыерларының гомуми баш санында сөтчелек юнәлешендәге нәселле сыерларның чагыштырма авырлыгы, процент | - | - | - | 23,5 | 23,6 | 23,7 | 23,8 | 23,9 | 24»; |

«Хуҗалык итүнең кече формаларына булышлык күрсәтү» ярдәмче программасында:

Ярдәмче программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программа паспорты

<table>
<tr><td>Ярдәмче программаның җаваплы үтәүчесе</td><td>Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаның максатлары</td><td>Хуҗалык итүнең кече формаларындагы авыл хуҗалыгы эшчәнлегенә һәм авыл хуҗалыгына карамаган эшчәнлеккә булышлык күрсәтү һәм аны алга таба үстерү, авыл җирлегендә тормыш сыйфатын яхшырту</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаның бурычлары</td><td>Кече эшмәкәрлек субъектлары санын арттыру һәм авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләр арасыннан җир кишәрлекләреннән файдалану нәтиҗәлелеген күтәрү өчен шартлар тудыру;<br>авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын модернизацияләү</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары</td><td>2013 – 2020 еллар</td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганаклар буенча җүлеп, ярдәмче программаны финанслау күләме</td><td>Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 3 250 489,2 мең сум тәшкил итә, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 897 561,0 мең сум һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 2 352 928,2 мең сум.<br>Еллар буенча ярдәмче программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү күләме түбәндәгеләрне тәшкил итә:
<table>
<tr><td rowspan="2">Ел</td><td colspan="2">Акча күләме, мең сум</td></tr>
<tr><td>Татарстан Республикасы бюджеты</td><td>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет</td></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td></tr>
<tr><td>2013</td><td>383 203,2</td><td>429 058,2</td></tr>
<tr><td>2014</td><td>167 100,0</td><td>468 502,8</td></tr>
</table>
</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td></td><td>
<table>
<tr><td>2015</td><td>180 000,0</td><td>*</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>180 000,0</td><td>*</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>180 000,0</td><td>*</td></tr>
</table>
</td></tr>
<tr><td></td><td>
<table>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>396 250,0</td><td>*</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>419 650,0</td><td>*</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>446 725,0</td><td>*</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>2 352 928,2</td><td>897 561,0</td></tr>
</table>
Ярдәмче программа юнәлешләре буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан бүленеп бирелә торган акча суммасы ел саен Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы нигезендә тәгаенләнә.<br>
* Федераль бюджет акчасы исәбеннән ярдәмче программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү күләме ел саен Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы Татарстан Республикасы белән төзи торган килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы бюджетыннан чыгымнарны финанслашу шартларында билгеләнә
</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр</td><td>Түбәндәгеләрне арттыру:<br>
дәүләт ярдәме белән үз хуҗалыкларын төзү һәм үстерү проектларын тормышка ашырган крестьян (фермер) хуҗалыклары, эшли башлаучы фермерлар санын – 1466 берәмлеккә;<br>
төзелгән яки төзекләндерелгән гаилә терлекчелек фермалары санын – 885 берәмлеккә;<br>
крестьян (фермер) хуҗалыклары милкенә рәсмиләштерелгән җир кишәрлекләре мәйданын 56,9 мең гектарга кадәр;<br>
2015 елдан 2020 елга кадәр кооперативлар тарафыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләреннән җыелган сөтне реализацияләү күләмен – 6 процентка;<br>
2015 елдан 2017 елга кадәр 20 авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының матди-техник базасын үстерү, данә.»;</td></tr>
</table>

ярдәмче программаның II бүлегендәге 2 бүлекчәдә:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күрсәтелгән максатларга ирешү өчен, кече эшмәкәрлек субъектлары санын арттыру, авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләр арасыннан җир кишәрлекләреннән

файдалану нәтиҗәлелеген күтәрү һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын модернизацияләү өчен шартлар тудыру кирәкр.»;

җиденче һәм сигезенче абзацларны тиешенчә тугызынчы һәм унынчы абзацлар дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле җиденче һәм сигезенче абзацлар өстәргә:

«2015 елдан 2020 елга кадәр кооперативлар тарафыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләреннән җыелган сөтне реализацияләүне – 6 процентка.

Шулай ук куелган бурычны тормышка ашыру 2015 елдан 2017 елга кадәр 20 авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының матди-техник базасын үстерүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.»;

Программаның 9 таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9 таблица

2013 – 2020 елларга «Хуҗалык итүнең кече формаларына булышлык күрсәтү» ярдәмче программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

Ярдәмче программаның максаты – хуҗалык итүнең кече формаларындагы авыл хуҗалыгы эшчәнлегенә һәм авыл хуҗалыгына карамаган эшчәнлеккә булышлык күрсәтү һәм аны алга таба үстерү, авыл җирлегендә тормыш сыйфатын яхшырту

| Бурыч исеме | Төп чаралар исеме | Үтәүчеләр | Соңгы нәтиҗәләрне җәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар мәгънәләре | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2012 (база) ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| Кече эшмәкәрлек субъектлары санын арттыру һәм авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләр арасыннан җир кишәрлекләреннән файдалану нәтиҗәлелеген күтәрү өчен шартлар тудыру | Эшли башлаучы фермерларга булышлык күрсәтү | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | Дәүләт ярдәме белән үз хуҗалыкларын төзү һәм үстерү проектларын тормышка ашырган крестьян (фермер) хуҗалыклары, эшли башлаучы фермерлар саны, берәмлек | 165 | 157 | 164 | 145 | 155 | 190 | 200 | 220 | 235 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү | | Төзелгән яки төзекләндерелгән гаилә терлекчелек фермалары саны, берәмлек | 189 | 100 | 100 | 110 | 110 | 115 | 115 | 115 | 120 |
| | | | Крестьян (фермер) хуҗалыклары милкенә рәсмиләштерелгән җир кишәрлекләре мәйданы, мең гектар | 54 | 54,6 | 55,4 | 56,1 | 56,9 | 56,9 | 56,9 | 56,9 | 56,9 |
| Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын модернизацияләү | Хуҗалык итүнең кече формаларына кредит бирү буенча дәүләт ярдәме | | Кооперативлар тарафыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләреннән җыелган сөтне реализацияләүне арттыру, % | - | - | - | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| | | | Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерү, данә | - | - | - | 5 | 7 | 8 | - | - | -»; |

«Техник һәм технологик модернизацияләү, инновацион үсеш» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортының «Ярдәмче программаның максатлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаның максатлары | Үсемлекчелектә, терлекчелектә һәм авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртүдә энергия ресурсларын саклау хисабына җитештерүне техник һәм технологик модернизацияләү нигезендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре продукциясенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм конкурентлык сәләтен үстерү»; |

ярдәмче программа паспортының «Ярдәмче программаның бурычлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаның бурычлары | Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан энергетика һәм хезмәт чыгымнарын киметүне һәм авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең инновацион активлыгын арттыруны тәэмин итүче югары технологияле машиналар һәм җиһазлар сатып алуны стимуллаштыру;<br>авыл хуҗалыгында биотехнологияне үстерү инфраструктурасын төзү»; |

ярдәмче программаның II бүлегендәге 2 бүлекчәдә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программаның максаты – үсемлекчелектә, терлекчелектә һәм авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртүдә энергия ресурсларын саклау хисабына җитештерүне техник һәм технологик модернизацияләү нигезендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре продукциясенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм конкурентлык сәләтен үстерү.»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан энергетика һәм хезмәт чыгымнарын киметүне һәм авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең инновацион активлыгын арттыруны тәэмин итүче югары технологияле машиналар һәм җиһазлар сатып алуны стимуллаштыру;»;

дүртенче абзацны төшереп калдырырга;

бишенче – унҗиденче абзацларны тиешенчә дүртенче - уналтынчы абзацлар дип санарга;

Программаның 11 таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 таблица

2013 – 2020 елларга «Техник һәм технологик модернизацияләү, инновацион үсеше» ярдәмче программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

Ярдәмче программаның максаты – үсемлекчелектә, терлекчелектә һәм авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртүдә энергия ресурсларын саклау хисабына җитештерүне техник һәм технологик модернизацияләү нигезендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре продукциясенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм конкурентлык сәләтен үстерү

| Бурыч исеме | Төп чаралар исеме | Үтәүчеләр | Соңгы нәтиҗәләрне җәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар мәгънәләре | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2012 (база) ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан энергетика һәм хезмәт чыгымнарын киметүне һәм авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең инновацион активлыгын арттыруны | Керемнәргә дәүләт ярдәме күрсәтү. Авыл хуҗалыгы техникасы паркын яңарту | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | Милекнең барлык формаларындагы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан яңа техника сатып алу күләмнәре – барлыгы, берәмлек: шул исәптән тракторлар | 600 | 600 | 650 | 700 | 750 | 800 | 850 | 900 | 950 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| тәэмин итүче югары технологияле машиналар һәм җиһазлар сатып алуны стимуллаштыру | | | ашлык җыю комбайннары | 200 | 200 | 220 | 240 | 260 | 280 | 300 | 320 | 340 |
| | | | тамыразык җыю комбайннары | 50 | 50 | 60 | 70 | 80 | 90 | 100 | 110 | 120 |
| | | | Чәчүлек мәйданының 100 гектарына авыл хуҗалыгы оешмаларының энергия белән тәэмин ителеше (тракторлар, комбайннар һәм үзйөрешле машиналар двигательләренең кушылган номиналь куәте), чәчүлекләрнең 100 гектарына ат көче | 158 | 141 | 142 | 143 | 144 | 145 | 146 | 147 | 148 |
| | | | Тормышка ашырылган инновацион проектлар саны, берәмлек | - | - | 1 | 1 | 2 | 2 | 2 | 3 | 3 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Авыл хуҗалыгында биотехнологияне үстерү инфраструктурасын төзү | Биотехнология-ләрне үстерү | | Үсемлекләрне саклау өчен био-логик чараларны һәм микробио-логик ашлама-ларны үсемлек-челектә куллану-ны үстерү, 2010 елга процент | 54 | 54,6 | 55,4 | 56,1 | 56,9 | 56,9 | 56,9 | 56,9 | 56,9 |
| | | | Биотехнологияләр ысуллары белән эшкәртелгән авыл хуҗалыгы җитеш-терүе калдык-ларының чагыш-тырма авырлыгы, процент | - | - | - | 10 | 10,5 | 10,7 | 10,9 | 11,2 | 11,5»; |

Программаның 12 таблицасында:

«Бурыч исеме» графасының 1 нче юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан энергетика һәм хезмәт чыгымнарын киметүне һәм авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең инновацион активлыгын арттыруны тәэмин итүче югары технологияле машиналар һәм җиһазлар сатып алуны стимуллаштыру».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков